| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БУИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

---

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
| 11.10.2023 | Буа шәһәре | № 252 Бк/к |

2023 елның IV кварталына торак урынның гомуми
мәйданының бер квадрат метры бәясе турында

«Россия Федерациясе гражданнарын һәркем өчен мөмкин булган һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем өчен мөмкин булган һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү «Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2017 елның 30 декабрендәге 1710 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган аерым чараларын гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2023 елның 29 августындагы 619 номерлы «2023 елның IV кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак бинаның гомуми мәйданының бер квадрат метры уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» боерыгы нигезендә, «Татарстан Республикасының Бәяләүчеләр союзы» коммерциясез партнерлыгының 2023 елның 23 августындагы 09 номерлы «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» тикшеренү нәтиҗәләрен исәпкә алып, «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын тормышка ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак сатып алу өчен социаль түләүләр бирү кагыйдәләренең 10 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елның IV кварталына яшь гаиләләргә торак сатып алуга яисә индивидуаль торак йорт төзүгә социаль түләү күләмен исәпләп чыгару өчен Буа муниципаль районы буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры нормативын 49 335,00 сум күләмендә билгеләргә.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2023 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче Л.Р. Шакирҗанов